РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН **ГЛАВА**
МЕЛЛЯ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘЛЛӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШЛЫГЫ**

*423976, Р.Т. Муслюмовский район, с.Мелля-Тамак, ул.Кооперативная,45*
*тел. (8-85556) 3-01-35*

с.Мәллә-Тамак «21» 01 2019 г

ПОСТАНОВЛЕНИЕ №1 КАРАР №1

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Мәллә-Тамак авыл җирлегендә**
**2019 елда үзара салым түләүне һәм җыюны оештыру һәм үзара салым акчалары тотыла торган төзекләндерү чаралары исемлеге турындагы карары**

"Җирле референдум, турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы , Мәллә-Тамак авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә 2019 елда Татарстан Республикиасы Мөслим районы Мәллә-Тамак авыл җирлегендә бер тапкыр түләү (үзара салым) акчаларын үз вакытында җыю максатыннан

Карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлегендә 2019 елга, референдумда тавыш бирү хокукына ия, 18 яше тулган һәр авыл җирлегендә яшәүчегә 1000 сум күләмендә бер тапкыр түләү (үзара салым) күләмен расларга.

2. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, I, II төркем инвалидлары, АДР да,хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар, нурлы авыру алган яки кичергән гражданнар, башка авырулар һәм инвалидлар өчен аны 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә кирәк.

3. Бер тапкыр түләү вакытын 2019 елның 10 апреленә кадәр расларга кирәк.

4. Авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карар буенча үзара салым акчаларын җыюны оештырырга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

5. Үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеген расларга. (1нче кушымта)

6. Авыл җирлеге башкарма комитетына үзара салым акчаларын исемлектәге тозекләндерү эшләренә тотарга һәм авыл җирлеге Советы алдында хисап тотарга.

7. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Мәллә-Тамак авыл җирлеге битендә түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://muslumovo.tatarstan.ru/rus/npa_malla.htm.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мөслим муниципаль районы Мәллә-Тамак
авыл җирлеге башлыгының № 1 карарына 1 кушымта
« 21» гыйнвар 2019 ел.

**Мәллә-Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы тотыла торган төзекләндерү буенча чаралар исемлеге:**

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
2. Халыкның ялын оештыру һәм хезмәт күрсәтү мәдәният оешмалары белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
3. Җирлек территориясендә физик культура, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру;
5. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә төзекләндерүне оештыру;
6. Урам-юл челтәре элементларына, җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү;
7. Җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, су бүлү;
10. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
11. Җирлек халкы күпләп ял итә алсын өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми кулланылыштагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле үтеп керүен тәэмин итү дә.
12. Җирлекләрнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;
13. Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыру..

Авыл җирлеге башлыгы Л.А.Игошева